КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЯДЕГӘР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
КАРАР

2021 елның 23 сентябре №23

Кукмара муниципаль районының Ядегәр авыл җирлегендә территориаль иҗтимагый үзидарә турында Ядегәр авыл җирлеге Советының 2007 елның 28 сентябрендәге 26 номерлы карары белән расланган Нигезләмәнең 13 статьясына үзгәрешләр кертү хакында

Кукмара муниципаль районы Ядегәр авыл җирлегендә территориаль иҗтимагый үзидарә турындагы Нигезләмәне «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга яраклаштыру максатларында Ядегәр авыл җирлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Кукмара муниципаль районының Ядегәр авыл җирлегендә территориаль иҗтимагый үзидарә турында Ядегәр авыл җирлеге Советының 2007 елның 28 сентябрендәге 26 номерлы карары белән расланган Нигезләмәнең 13 статьясына , 4 пунктка түбәндәге эчтәлекле 7 нче пуктчаны өстәп, үзгәрешләр кертергә:

7) инициативалы проектны тикшерү һәм аны хуплау мәсьәләсе буенча карар кабул итү.»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча, махсус мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга, шулай ук «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Ядегәр авыл җирлеге башлыгы А .Н.Фәйзуллин